**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ТАШКИЧУЙСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГОРАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423959, Республика Татарстан,
Ютазинский район, деревня Малые Уруссу,
улица Советская, дом 18а.
тел. 85593 4-23-10, факс 85593 4-23-40

423959, Татарстан Республикасы,
Ютазы Районы, Кече Урыссу авылы,
Совет урамы, 18а йорты.
эл.адрес Tash.Utz@ tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**10 февраль 2015 ел** **№ 2**

Ютазы муниципаль районы Ташкичү
авыл җирлеге башкарма комитетының
2014 елның 5 ноябрендәге 21 санлы
карарына үзгәреш кертү турында

2014 елның 31 декабрендәге «Россия Федерациясе чикләрендә хәрәкәт итү, яшәү урынын сайлау ирегенә Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 387–ФЗ санлы, 2013 елның 28 декабрендәге Федераль законның 2 маддәсе һәм Ютазы районы прокурорының 2015 елның 12 гыйнварындагы 02-08-01-2015 санлы протесты законлы көченә керүгә бәйле рәвештә:

1. Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетының «муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»2014 елның 5 ноябрендәге 21 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетында белешмә(өземтә) бирү буенча хезмәт күрсәтү административ регламентының 1 нче кушымтасына муниципаль хезмәт күрсәтү стандартының 2.5 пункты «муниципаль хезмәт күрсәтү алу өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган документларның тулы исемлеге» 2 нче кушымтасы түбәндәге редакциядә бәян ителергә:

«1.Яшәү урыныннан белешмә, өйдән китаптан өзекләр, элеккеге яшәү урыныннан белешмәләр алу өчен:

1.1. Шәхесне раслаучы документлар.
1.2. Өй китабы.
1.3. Шәхси торак йортка хокуклар турында Документ (хокукны дәүләт теркәве турында таныклык яисә шәхси торак йортка техник (кадастр) паспорт, яисә Ростехинвентаризациядән хокук ияләре турында белешмә-Федераль БТИ, Татарстан Республикасы буенча филиал).

2.Гаилә составы турында белешмә алу өчен:

2.1. Шәхесне раслаучы документлар.

2.2. Өй китабы.
2.3. Соралган адрес буенча теркәлгән барлык гаилә әгъзаларының туганлыгын раслаучы документлар (паспортлар, туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык).

3.Үлем көнендә үлгән кешенең яшәү урыныннан белешмә алу өчен:

3.1. Шәхесне раслаучы Документ.
3.2. Өй китабы.
3.3. Үлем турында таныклык (оригинал).
3.4. Соралган адрес буенча теркәлгән барлык гаилә әгъзаларының туганлыгын раслаучы документлар (балалар туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык).

4.Хуҗалык китабы ннан өзек алу өчен:

4.1.хуҗалык китабы ннан өзек бирү турында ирекле формада гариза;
4.2. Хокук иясенең шәхесен раслаучы документ;
4.3.үлгән җир участогы хуҗасының үлем таныклыгының күчермәсе;
4.4.җир кишәрлегендә урнашкан йортка (башка объектлар булса) хокук билгеләүче документларның күчермәләре;
4.5. җир участогында урнашкан йортның адрес номеры күрсәтелгән фотосы.

5.Физик зат вәкиле өчен гариза бирүче исеменнән гамәлләр башкару вәкаләтләрен раслаучы нотариаль расланган документның күчермәсен тапшырырга кирәк.
6.Исемдә китерелгән Документлар документларның тиешле оригиналы белән бергә тапшырыла.
7.Гаризалар, документлар һәм документларның күчермәләре бер экземплярда бирелә.»

2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының Интернет челтәрендәге мәгълүмат стендында һәм рәсми сайтында бастырып чыгарырга www.yutaza.tatar.ru
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы: Р.К.Вәлиев.